ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 5 марты** **Чистай шәһәре** **№ 113**

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы Башкарма комитетының резерв фонды
акчаларын тоту тәртибе турындагы нигезләмәне
раслау хакында» 2012 елның 16 ноябрендәге
887 номерлы карарын үтәү үзенчәлекләре турында

Чистай шәһәр прокуратурасының 2021 елның 26 февралендәге 02-08-02-2021 протестын карап чыканнан соң, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын китерү максатларында, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2020 елның 15 октябрендәге 327-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Башкарма комитетыны

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды күләмен арттыру очракларына 2022 елның 1 гыйнварына кадәр 2.2 пункты Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 16 ноябрендәге 887 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәләре кагылмый дип билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан чыгымнарны югарыда күрсәтелгән үзгәрешләр нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен кертә дип билгеләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль

районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов